ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» апреля 2024 ел № 101

«2022-2025 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Әгерҗе муниципаль районы комплекслы программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 13.01.2022 елның 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (31.10.2022 елның 262 номерлы, 12.12.2023 елның 378 номерлы карар редакциясендә)

Әгерҗе муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту, гражданнарның иминлек дәрәҗәсен күтәрү аша җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү өчен нигез булдыру кысаларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2025 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Әгерҗе муниципаль районы комплекслы программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 13.01.2022 елның 13 номерлы карарына (31.10.2022 елның 262 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программа чаралары» 6 нчы бүлекнең «1 нче бурыч. Татарстан Республикасырыерҗе муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе» бүлекчәсен түбәндәге пунктлар белән тулыландырырга:

1 нче бурыч: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе

| Төп чараларның атамалары | Башкаручы | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткече, үлчәү | Индикаторларның кыйммәте | Җирле бюджет акчалары исәбенә финанслау (мең сум) |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | берәмлеге | 2020 (төп) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1.8. Россия Федерациясе территориясендә легаль булмаган чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган, шул исәптән законсыз рәвештә хезмәт эшчәнлеген алып баручы затларны ачыклау буенча уртак оператив-профилактик чаралар үткәрү. | ОМВД, ЦЗН Әгерҗе шәһәре | 2024-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.9. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан хокук бозуларны профилактикалау һәм аларның Россия Федерациясендәге хокукый хәле, шул | ОМВД, "Әгерҗе хәбәрләре" газетасы редакциясе | 2024-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исәптән вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм яшәүгә рөхсәт рәсмиләштерү, Россия Федерациясе гражданлыгын алу мәсьәләләре буенча ММЧда аңлату эше алып барырга | | | | | | | | | | | | |
| 1.10. Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган, наркомания, йогышлы авырулар белән авыручы кешеләрне ачыклау буенча Сәламәтлек саклау учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру. Вакытлыча яшәү рөхсәтен, эш рөхсәтен юкка чыгару буенча чаралар күрергә. | ОМВД, ГАУЗ "Әгерҗе РҮХ" ДАССО | 2024-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.11. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның торышын контрольдә тотуны, миграция исәбендә булмаган затларны ачыклауны оештыру. | ОМВД | 2024-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**